РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«26» февраль 2019 ел Буа шәһәре № 59/ИК-п

«Мәктәпкәчә белем бирү (балалар бакчалары)
төп гомумбелем программасын гамәлгә ашыручы
белем бирү оешмаларына балаларны исәпкә алу һәм теркәү»
муниципаль хезмәтен күрсәтү административ регламентына
үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законы, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законы, Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2015 елның 10 мартындагы 1389/15 номерлы боерыгы белән расланган «Мәктәпкәчә белем бирү (балалар бакчалары) төп гомумбелем программасын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларына балаларны исәпкә алу һәм теркәү» муниципаль хезмәтен күрсәтү административ регламентының якынча формасына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 26 декабрендәге 1975/18 номерлы боерыгы нигезендә, Буа муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТТЕ:

1. Буа муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 16 августындагы 367-п номерлы карары белән расланган «Мәктәпкәчә белем бирү (балалар бакчалары) төп гомумбелем программасын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларына балаларны исәпкә алу һәм теркәү» муниципаль хезмәтен күрсәтү административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 3 пунктта:

3.4.4 пунктчасын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Ташламаның гамәлдә булуы билгеләнгән срогы үтү белән, Гариза бирүчегә Оешмага чираттан тыш яки беренче чиратта теркәлү хокукын расларга кирәк.»;

1.2. 3.4.6 пунктчасында өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Уку елы дәвамында буш урыннар булганда, Административ регламентның 3 пунктында каралган тәртип нигезендә, Оешманы комплектлаштырып бетерү башкарыла.»;

1.3. 3.4.6 пунктчасының дүртенче абзацын бетерергә;

1.4. 3.4.6 пунктчасының алтынчы абзацында «5 эш көненнән дә күбрәк түгел» сүзләрен «бер эш көненнән дә күбрәк түгел» дигән сүзләргә алыштырырга;

1.5. 3.5.2 пунктчасының өченче абзацында «3 ай эчендә» дигән сүзләрне «Бер ай эчендә» дигән сүзләргә алыштырырга;

1.6. 3.5.4 пунктчасының беренче абзацын түбәндәге эчтәлектәге җөмлә белән тулыландырырга:

«Теркәлүнең теләгән көненә үзгәртү Гариза бирүче юлламадан баш тарту турында мөрәҗәгать иткән көннән дә иртәрәк булмаган көнгә башкарыла.»;

1.7. 3.5.5 пунктчасының беренче абзацында «Оешма җитәкчесе Системада гаризага «Килмәде» статусын бирә» сүзләрен «Системада гаризага «Килмәде» статусы бирелә» сүзләре белән алыштырырга;

1.8. 3.5.5 пунктчасының беренче абзацын түбәндәге эчтәлекле җөмлә белән тулыландырырга:

«Раслаган вакытта теркәлергә теләгән дата Гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көннән дә иртәрәк булмаган датага муниципаль хезмәтне алуга ихтыяҗны раслау белән үзгәртелә.»;

1.9. 3.6.2 пунктының икенче абзацында «3 айлык срокта» сүзләрен «бер айлык срокта» сүзләренә алыштырырга;

1.10. 3.6.2 пунктының беренче абзацын түбәндәге эчтәлекле җөмлә белән тулыландырырга:

«Раслаган вакытта теркәлергә теләгән дата Гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көннән дә иртәрәк булмаган датага муниципаль хезмәтне алуга ихтыяҗны раслау белән үзгәртелә.».

2. Әлеге Карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән законлы көченә керә һәм http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары – «Буа муниципаль районы Мәгариф идарәсе» МКУ җитәкчесе И.Ф.Ханбиковка йөкләргә.

Буа муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе
вазыйфасын башкаручы И.Г. Гыйззәтов